хәтер-хатирә

# ГАЗИЗ АБЫЙ ЯДКАРЕ

**21 августта шәһәребездә яшәп иҗат иткән танылган татар язучысы Газиз Кашаповның 70 еллыгы җитә. Аның "Сәмум җиле", "Солдат иртә ир була", "Җир җылысы" повестьлары, "Язмышыңа ышан" романы заманында популярлык казанды. Аның китапларын кулдан-кулга йөртеп укыдылар. Газиз Кашапов җитмешенче еллар ахырында Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеген җитәкләде. 1991 елның 30 августында арабыздан бакый дөньяга күчте.**



1978 ел, КАМАЗ заводларының гөрләп эшләп торган чоры, эшкә дә, иҗатка да вакыт таба торган яшь чакларым... Шигырьләрем республика, шәһәр газета-журналларында даими басылып торса да, Чаллы язучылар оешмасына килергә җөрьәт итми идем. Инде Татарстан телевидениесе игълан иткән "Яшь поэзия турниры"нда икенче урынны алгач, үземне заводтан эзләп таптылар.

— Сине Чаллы язучылар оешмасына чакыралар, — диде цех башлыгы. — Бармый калма, җитди нәрсә булуы бар.

Мине шунда җибәрер өчен икенче көнне эштән азат иттеләр. Иртәниртүк язучылар оешмасы урнашкан 3нче комплекстагы йортны эзләп киттем.

— Кем һуң һин, нәмәгә килдең? — дип каршы алды бер ханым, мин аның башкорт шагыйрәсе Фирдәвес Бәширова икәнлеген соңыннан гына белдем. — Газиз Кашапов озакламай килеп етәр.

Бер сәгать чамасы көтеп тилмергәч, ишектән олпат гәүдәле, сакалмыеклы, күз карашын бөркет кебек түргә төбәп бер абзый килеп керде. Аның турында: "Әллә урысмы бу?" — дип уйларга өлгермәдем:

— Исәнмесез, — дип татарча көр тавыш белән эндәште ул. — Мине көтәсезме?

Беренче карашка әллә нинди серле, тәкәббер күренгән абзый, сөйләшә торгач, гади, эчкерсез кеше булып чыкты. Газиз Кашаповны китаплары, газета-журналларда басылган әсәрләре буенча белсәм дә, үзен болай тыйнактыр дип уйламый идем.

Газиз абый башта ашыкмый гына хәл белеште, кайда эшләвемне сорашты, иҗатым белән кызыксынды.

— "Татарстан яшьләре"нә Разов фамилиясе белән мәкаләләр яза торган егет син буласыңмыни? — диде. Язучылар берлеге бүлеге җаваплы сәркатибе минем язучылар оешмасына "Ләйсән" әдәби берләшмәсенә йөрүемне сорады. Аннан үзе белән бераз таныштырды. Иҗатка вакыт җитмәве, заман белән янәшә атлау өчен көн-төн өстәлдән аерылмыйча язарга кирәклеге турында сөйләде. Газиз абый миңа киңәшләр бирде: иҗат ит, язганнарыңны чыгар, гомер үтә дә китә, барысына да өлгерергә кирәк, язучылар оешмасына 30 яшькә кадәр керә алмасаң, алга таба ул турыда уйлыйсы да юк, диде. Мин олы язучыны бирелеп тыңладым, әңгәмәбез ахырында иҗат итүнең авыр, җаваплы хезмәт икәненә тәмам ышандым.

Шуннан соң үткән-сүткәндә хәл белешергә бик еш Газиз абый Кашапов янына кереп йөри башладым. Шунда хисапчы булып эшләүче, барлык язучыларның тормышларын, аларның әсәрләрен биш бармагы кебек белгән Нәсия Нурмиева белән дә гәпләшә идек. Ул Газиз Кашаповның яңа әсәрләре хакында үз фикерен әйтеп, теге яки бу китабын укырга тәкъдим итә иде.

Газиз Кашапов җитәкләгән чорда Чаллы язучылар оешмасы гөрләп торды. "Ләйсән" әдәби берләшмәсе җыелышларына яшь һәм башлап язучылар белән бергә танылган иҗат әһелләре катнашуы да зур дәрәҗә иде. Ул чакта без өлкәннәрнең һәрдаим ярдәмен тоеп, киңәшен тотып яшәдек, иҗат иттек. Профессиональ каләм ияләре үз җыелышларына яңа гына борын төртеп килә торган язучыларны чакыра иделәр. Газиз абыйның: "Өйрәнә торсыннар, белеп үссеннәр", дигәне истә калган.

Ул, йөрәгә авыртса да, актив иҗат итте. Миңа бервакыт аның квартирасына ниндидер бер язма барып алырга туры килде. Иҗат бүлмәсе китаплар белән шыплап тулган, анда папка, монда бер кочак кәгазь — менә нинди була икән остаханә!

"Нур" газетасы редакциясендә эшләгәндә Газиз Кашапов һәрвакыт безгә килә, яңа шигырьләрен басарга калдырып китә иде. Аның белән рәхәтләнеп дөнья хәлләре турында сөйләшеп утырган чаклар хәтердә. Ул шул чорда Газиз Кашап-Үзиле исеме белән әсәрләрен бастырды. Аның шигърияте романповестьлары кебек эчтәлекле, фәлсәфи иде. Газиз абый тормышны яратып, аның бөтен нечкәлекләрен белеп язды, шул чорның иң шәп каләм осталарының берсе булды.

— Табиблар җәяү йөрергә куша, кая барсам да, гел тәпи-тәпи атлыйм, — диде ул беркөнне килгәч. Авыруы каты булса да, оптимистик рухлы кеше иде. Ябыкты, очкын чәчеп торган бөркет күзләре эчкә батты, ә шулай да мишәрләрдә генә була торган чаялыгын, үткенлеген җуймады.

Газиз абый Кашапов бүген дә ул мәһабәт гәүдәле ир-егет булып күз алдымда басып тора. Ә иҗат иткән әсәрләре — халкыбызның совет чорындагы тормыш сәхифәләре — аерым кыйммәткә ия. Чаллы шәһәре тарихында якты эз калдырган олуг шәхес, язучы Газиз Кашапов исемен мәңгеләштерү турында бүген уйлаучы да юк — шунысы аянычлы. Ә бит, үткәннәрне онытканнарның киләчәге дә юк, диләр. Газиз абый рухына дога кылырга гына кала...

**Мирһади РАЗОВ.**